КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 8 декабрь г.Казань № 1102

Nатарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл торак пунктларына, яисә шәһәр тибындагы бистәләргә, яисә 50 мең кешегә кадәр халкы булган шәһәрләргә эшкә килгән (күченеп килгән) укытучыларга бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве турында» 2020 ел, 26 февраль, 149 нчы карары белән расланган Авыл торак пунктларына, яисә шәһәр тибындагы бистәләргә, яисә 50 мең кешегә кадәр халкы булган шәһәрләргә эшкә килгән (күченеп килгән) укытучыларга бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве алуга дәгъва белдерүчеләрне конкурс нигезендә сайлап алу турында нигезләмәгә үзгәреш кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 28 апрель, 345 нче карары үз көчен югалтуын тану хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл торак пунктларына, яисә шәһәр тибындагы бистәләргә, яисә 50 мең кешегә кадәр халкы булган шәһәрләргә эшкә килгән (күченеп килгән) укытучыларга бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве турында» 2020 ел, 26 февраль, 149 нчы карары белән расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 28 апрель, 345 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Авыл торак пунктларына,

яисә шәһәр тибындагы бистәләргә, яисә 50 мең кешегә кадәр халкы булган шәһәрләргә эшкә килгән (күченеп килгән) укытучыларга бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве алуга дәгъва белдерүчеләрне конкурс сайлап алуы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.7. Конкурста сайлап алуны үткәрү тәртибе:

төбәк операторы тарафыннан гаризалар һәм документларны кабул итү һәм теркәү - 10 гыйнвардан 15 апрельгә кадәр (чараны гамәлгә ашыру чорында ел саен);

конкурс сайлап алу критерийлары нигезендә гаризаларга һәм документларга эксперт бәяләмәсен үткәрү - 19 апрельдән 30 апрельгә кадәр (чараны гамәлгә ашыру чорында ел саен);

конкурс комиссиясе тарафыннан конкурста сайлап алу җиңүчеләрен билгеләү (беркетмә нигезендә) - 1 майдан 15 майга кадәр (чараны гамәлгә ашыру чорында ел саен);

конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре буенча дәгъвачылар рейтингының вәкаләтле органының һәм төбәк операторының рәсми сайтларына - 15 майдан 17 майга кадәр (чараны гамәлгә ашыру чорында ел саен);

конкурс нигезендә сайлап алынган җиңүчеләр сайлап алынган гомуми белем бирү оешмасына аның администрациясе һәм педагогик коллективы белән танышу максатыннан бару (күченү һәм эшкә урнашу белән бәйле мәсьәләләрне хәл итү (гомуми белем бирү оешмасы урынына кадәр бару һәм яңадан эшкә урнашуга бәйле мәсьәләләрне хәл итү)) - 18 майдан 15 июньгә кадәр (чараны гамәлгә ашыру чорында ел саен);

конкурс нигезендә сайлап алынган җиңүчеләр исемлеген раслау турында вәкаләтле орган боерыгын бастырып чыгару - 20 июньгә кадәр (чараны гамәлгә ашыру чорында ел саен);

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә вәкаләтле органның һәм төбәк операторының рәсми сайтларында конкурс нигезендә сайлап алынган җиңүчеләр исемлеген раслау турында вәкаләтле органның боерыгын урнаштыру - 28 июньгә кадәр (чараны гамәлгә ашыру чорында ел саен).»;

5.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.5. Даими яшәү урынына күчү турында карар кабул иткән конкурс сайлап алуында җиңүчеләр агымдагы елның 1 августына кадәр вәкаләтле орган боерыгы белән расланган форма буенча күчеп китүгә ризалык бирә һәм алучы белән хезмәт шартнамәсе төзегән вәкаләтле орган һәм гомуми белем бирү оешмасы арасында агымдагы елда бер мәртәбә компенсация түләүләре алу өчен вәкаләтле орган боерыгы белән расланган форма буенча бер тапкыр компенсация түләве турында (ирекле рәвештә) өч яклы килешү төзи.

Агымдагы елның 15 августына гомуми белем бирү оешмасы белән хезмәт шартнамәсен төземәгән конкурс сайлап алуында җиңүчеләр конкурс комиссиясе карары белән муниципаль район мәгариф идарәсе җитәкчесенең хаты нигезендә конкурста сайлап алу җиңүчеләре исемлегеннән төшереп калдырыла. Бер үк вакытта конкурс комиссиясе рейтинг буенча иң күп балл җыйган дәгъвачыга чарада катнашырга тәкъдим итә.

Исемлектән төшереп калдырылган рейтинг буенча сайлап алу җиңүчесе аны гамәлгә ашыруның бөтен чоры дәвамында бер мәртәбә компенсация түләүләре алуга чарада катнашу хокукыннан мәхрүм ителә.

Конкурста сайлап алуда җиңүчеләр хезмәт шартнамәсенә кул куюдан баш тартканда яисә конкурс процедураларын уздыру йомгаклары буенча урнаштырылган вакансияләргә кандидатлар булмаганда вәкаләтле орган конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе нигезендә өстәмә конкурс процедуралары уздыра, яңа ачылган вакансиягә дәгъвачыларны конкурс нигезендә сайлап алуны озайту срогын яисә буш вазыйфалар исемлегендә алмаштыру юлы белән ачык башкарыла.

Вәкаләтле орган вакантлы вазыйфалар исемлегенә үзгәрешләр кертү юлы белән вакансияләрне яңадан бүлү турында боерык чыгара. Вакансияләрне яңадан бүлү турындагы тәкъдимнәр конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсендә чагыла, һәм яңадан бүлешү гомуми белем бирү оешмаларында вакансияләрне бер гомуми белем бирү оешмасында үзгәртү яисә кертү (төшереп калдыру) юлы белән алып барылырга мөмкин.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл торак пунктларына, яисә шәһәр тибындагы бистәләргә, яисә 50 мең кешегә кадәр халкы булган шәһәрләргә эшкә килгән (күченеп килгән) укытучыларга бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве турында» 2020 ел, 26 февраль, 149 нчы карары белән расланган Авыл торак пунктларына, яисә шәһәр тибындагы бистәләргә, яисә 50 мең кешегә кадәр халкы булган шәһәрләргә эшкә килгән (күченеп килгән) укытучыларга бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве алуга дәгъва белдерүчеләрне конкурс нигезендә сайлап алу турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 2020 ел, 28 апрель, 345 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин